БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 02 2024 ел № 87

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 320 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану, торглар үткәрмичә генә аренда, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 16 пунктында «әлеге күчемсез милек объектлары бирелгән» сүзләрен «дәүләт яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирелгән,» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2021 елның 19 августындагы 261 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. 2.5.1 пунктында түбәндәге эчтәлекле 11 пунктчаны өстәргә:

«11) әгәр мондый яраштыру Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренешен яраштыру »;

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 258 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.1. 2.5.1 пунктында 4 һәм 6 пунктчаларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 12 августындагы 251 номерлы карары белән расланган арендалана торган мөлкәтне сатып алуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының арендалана торган милеккә өстенлекле хокукын гамәлгә

ашыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. 2.9.2 пунктында «күчемсез» сүзен «арендага бирелә торган» сүзенә алмаштырырга, «арендага бирелә торган» сүзен «мондый» сүзенә алмаштырырга,

4.2. 2.9.3 пунктына «күчемсез мөлкәт өчен һәм күчемле мөлкәт өчен кимендә өч ел» сүзләрен өстәргә;

5. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2009 елның 19 мартындагы 103 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетында гражданнарның һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач районы башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов